Музей экспозиция, экскурсия, фәнни-тикшеренү юнәлешләрендә эш алып бара. Бүгенге көндә музейда 382 экспонат бар. Алар халык көнкүреше предметлары, Бөек Ватан сугышы каһарманнары турында мәгълүмат, күмәк хуҗалык тарихы, авылның күренекле шәхесләре турында мәгълүмат,  меңеллык тарихлы мәдрәсәсе тарихы, тарихи казылмаларны бергә туплаган. Музейда тупланган материаллар безгә авылның күпьеллык тарихы, авыл мәдрәсәсендә белем алган бөек шәхесләр, XVII-XX гасырларда авыл халкының көнкүреше, сугыш



